ЯРДӘМ КИРӘКМЕ?
Балтачта туган телләрне саклау һәм үстерү турында сөйләштеләр
> 3

ХЫЯЛ ЯШӘТӘ
Язмышлары газетада бәян ителгән балалар белән без даими элемтәдә
> 3

УКЫСЫННАР ГЫНА!
Китапханәче Эльвира Әхмәтҗанова китапны өйдән-өйгә йөртеп укыта
> 4

«ТАТАР СҮЗЕ»
Татар телен саклау һәм үстерүнең бик тә мөһим һәм әһәмиятле юлы бу
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 76 (28849) | Чәршәмбе | 1 июнь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

МАТУР ТУГАНДА

ЧӘЧҮ СОҢАРДЫ, ӘММА КУРКЫНЫЧ ТҮГЕЛ

Яңгырлы һәм салкын һава торышы булу сәбәпле, быел чәчү эшләре ике атнага соңара. Кайбер культураларны чәчү вакыты тоткарланса да, авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров сүзләренчә, моның уңышка әллә ни йогынтысы булмаячак.

«Вт» архивыннан

– Иртә язын чәчелә торган ашлык культуралары, шул исәптән кукуруз, көнбагыш һәм шикәр чөгендере, соя утыртыр өчен уңышлы вакыт узып бара. Көнбагыш 95–105 көн эчендә өлгерә. Шул ук вакытта әлеге культураны җыеп алыр өчен күп вакыт кирәк. Бүген әле рапс, борчак һәм карабодай утырту өчен вакыт бар. Утыртырга соңга калган культураларны алар белән алыштырырга тәкъдим итәбез. Аларга сорау елдан-ел арта. Шулай булгач, соңга калуда куркыныч юк. Төп чәчү эшләрен төгәлләп киләбез. Алга таба күп нәрсә һава торышына бәйле. Яңгырлар язгы кыр эшләрен бераз тоткарлады, ләкин дым запасы да яхшы гына тулыланды, – диде министр.

Гидрометеорология үзәге мәгълүматлары буенча, апрель – майда республика буенча уртача 139 мм явым-төшем булган. Бу – күпьеллык уртача күрсәткечләр ике тапкыр арткан дигән сүз.

Утыртырга соңга калган культураларны алыштырырга туры килсә дә, ашлык белән тәэмин ителешкә зур йогынтысы булмаячак, дип ышандырды министр.

– Алар әллә ни зур мәйданнар түгел. Һәр хуҗалык эш планын үзенә яраклаштыра. Маллар күп тотучылар өчен терлек азыгы әйбәт кенә булачак. Быел күпьеллык үләннәрнең беренче каты яхшы булырга тиеш, – диде ул.

Әлеге вакытта республикада 1,68 млн гектар мәйданда язгы культуралар чәчелгән. Бу – барлык мәйданнарның 91 проценты дигән сүз. Инде эшләрен төгәлләүче районнар да бар. Әтнә, Лениногорск, Зәй, Биектау, Актаныш – әнә шундый алдынгылар рәтендә. Министр бүген-иртәгә эшләрен төгәлләячәк районнарны да атады. Алар – Мөслим, Алабуга, Балтач, Тәтеш, Сарман, Тукай һәм Спас районнары. 5 июньгә исә Татарстанда чәчүне барлык районнар да төгәлләр, дип өметләнә министр.

Шул ук вакытта чәчүгә иртә чыгып, эшләрен бүгенгә кадәр тәмамламаучылар да бар.

– Географик урынына бәйле рәвештә, Питрәч, Саба, Югары Ослан, Әгерҗе районнары чәчүгә соңрак керешкән иде. Ә Бөгелмә, Баулы, Чүпрәле районнары, эшне беренчеләрдән булып башлап, чәчү эшләрен тәмамларга тиешләр иде, ләкин күрсәткечләре төньяк районнар дәрәҗәсендә генә, – диде Марат Җәббаров.

Аның сүзләренчә, эшне болай озакка сузу һава торышына гына бәйле түгел. Аны техника җитәрлек булмау, запас частьлар белән авырлыклар булу да тоткарлый.

Чәчү – болай да мәшәкатьле һәм чыгымлы эш. Быел хуҗалыкларга билләрен тагын да кысыбрак буарга туры килде. Барыбызга да мәгълүм сәбәпләр аркасында, ашлама, орлык, энергия ресурслары, запас частьларга бәяләр шактый күтәрелде. Шуңа күрә хуҗалыкларның чәчү, кыр эшләренә тотылган чыгымнары, узган ел белән чагыштырганда, бик нык артты, дип бәяләде министр.

Санкцияләр кертелгәннән соң, хуҗалыкларга орлыклар белән тәэмин ителү мәсьәләсендә дә шактый гына өстәмә мәшәкатьләнергә туры килгән иде.

– Быелга җитәрлек орлык бар, – дип аңлатма бирде Марат Җәббаров. – Аларның барысы да чит илдән кертелде. Әлеге вакытта башка илләр, җитештерүчеләр белән сөйләшүләр алып барабыз. Киләсе елга ничек булыр, әлегә бу сорауга минем ачык кына җавабым юк. Билгеле, борчу бар. Үз илебездә җитештерелгән орлыкларның сыйфаты чит илнекеләрдән калыша. Әгәр аларны алып керә алмасак, Россия үз орлыклары белән тулысынча тәэмин итә алачак.

Күпчелек хуҗалыкларның терлек азыгы җыя торган комбайннары да әзер. Бу мәсьәләдә Югары Ослан, Әгерҗе, Буа һәм Алексеевск районнары гына графиктан калыша.

Дүшәмбе көнне Бөтенроссия ашлык форумында Россия авыл хуҗалыгы министры Дмитрий Патрушев быел рекордлы күрсәткечләргә якын уңыш алачагыбызга ышанычын белдергән иде. Марат Җәббаров та моңа өметләнүен яшермәде.

– Узган ел да бик матур башланган иде югыйсә. Кышы да карлы, дымы да җитәрлек иде. Тик кояш чыкты да көзгә кадәр кыздырды. Узган ел хуҗалыкларга да бик авыр булды. Шуңа күрә быел яхшы уңыш булсын иде, дип телибез. Моның өчен бик күп эш эшләнә. Мул уңыш алып, аны яхшы бәядән сатарга өметләнеп торабыз, – диде ул.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Күпбалалы гаиләләр арта

Ун ел эчендә Татарстанда күпбалалы гаиләләр саны 66 процентка артып, 24807дән 40500гә җиткән. Бу хакта Рөстәм Миңнеханов белдерде. Президент искә төшереп үткәнчә, республикада ана абруен үстерү һәм аңа ярдәм итү өчен «Ана даны» медале гамәлгә куелды. Быел исә яңа бүләк – «Ата-ана фидакарьлеге» дигән дәүләт медале пәйда булды. Ул 7 һәм аннан күбрәк бала тәрбияләүче гаиләләргә бирелә. Мондый гаиләләргә шулай ук 100 мең сум күләмендә премия бирелә.

10 процентка үсә

1 июньнән республикада җан башына яшәү минимумы күләме арта: моңа кадәр ул 10756 сум булса, хәзер, 1076 сумга ишәеп, 11832 сум тәшкил итәчәк.

Хөкүмәт карары проекты «Рәсми Татарстан» порталына урнаштырылган. Аның нигезендә, эшкә сәләтле халык өчен әлеге күрсәткеч 12896 сумга (моңа кадәр 11724 сум иде), пенсионерлар өчен – 10175 сум (9250 сум иде), балалар өчен 11476 сумга (10433 сум) җитәчәк.

Бу чара Россия Президенты Владимир Путин кушуы буенча күрелә. 25 майда ул, эшләмәүче пенсионерларның пенсиясе, яшәү минимумы һәм минималь хезмәт хакы күләме июнь аеннан 10 процентка артачак, дип белдерде.

Сәфәр генә түгел

Казан «Больше, чем путешествие» программасында катнашучылар өчен иң популяр юнәлешләрнең берсенә әйләнгән. Программаны «Россия – мөмкинлекләр иле» Президент платформасы, «Белем» җәмгыяте, Ростуризм, Росмолодежь, Фән һәм югары белем министрлыгы тормышка ашыра. Илнең күренекле урыннары белән танышу гына түгел, бәлки әле экология, фән, бизнес өлкәләрендә, иҗтимагый тормышта үзеңне күрсәтү, яңага өйрәнү мөмкинлеге дә бирердәй тиңдәшсез программа бу. Президент платформасының 26 проекты җиңүчесенә һәм призерларга әнә шундый сәфәр бүләк ителгән.

Узган елның сентябреннән быел майга кадәр барлыгы 23 меңнән артыграк кеше ил буйлап сәфәр кылган инде. Шуның 1134е Казанда булып киткән. Сәяхәтчеләр Иске Татар бистәсе, Казанның борынгы урамнарында күпгасырлык корылмалар, гыйбадәтханәләр белән хозурланган. Алар шулай ук Иннополис фән шәһәрчегенә барып, алдынгы технологияләр белән танышкан, аларны тормышта ничек кулланып булуын күргән.

Программа 4 елга исәпләнгән. Ул Россия Президенты Владимир Путинның кушуы буенча гамәлгә ашырыла. Аның өчен һәр ел саен 2 миллиард сумнан артыграк акча бирелә. Программада төрле яшьтәге кешеләр катнаша. Иң өлкәненә – 90 яшь.

Аш-су бәйрәменә килегез

4 июнь көнне Казанның Аккош күлендә аш-су фестивале узачак. Татарстан башкаласы эшмәкәрләре башлангычын мэрия, Киров һәм Мәскәү районнары хакимияте хуплаган. Оештыручылар әйтүенчә, гастрономик бәйрәмдә төрле ризыклар тәкъдим ителәчәк. Табигать кочагында ял итүчеләрнең яраткан ризыгы – шашлык, шаурмадан тыш, башка аш-сулар да тәкъдим ителәчәк. Бәяләре дә төрлечә булачак.

Фестивальдә барлыгы 35 пешекченең аш-су әзерләве күздә тотыла. Җәмәгать вәкиле Михаил Кузнецов әйтүенчә, алар барлыгы 10 меңнән артыграк кешене сыйлаячак. Бирегә пешекчеләрнең иң яхшылары киләчәк. Моннан тыш фестивальдә су тамашасы, спорт уеннары, палаткаларда ял итү, артистлар чыгышлары булачак.

Табиб төтеннән коткара

Татарстанда 2600дән артыграк кеше табибка күренгәннән соң тәмәкене ташлаган. 2013 елдан Республика клиник наркология диспансерында тартудан котылырга ниятләүчеләр өчен махсус кабинетлар эшләп килә. Диспансерның матбугат хезмәтеннән хәбәр ителгәнчә, соңгы 5 ел эчендә 3300дән артыграк кеше табиб-наркологка мөрәҗәгать иткән. Хәзерге вакытта наркодиспансерның Казан, Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт, Бөгелмә һәм Яшел Үзән филиаллары белгечләре тартучыларны никотинга бәйлелектән коткару буенча эшли. Табиблар тәмәкедән аерылырга теләүчеләрне бушлай кабул итә. Алар дарусыз, шулай ук дарулар ярдәмендә тәмәкене ташлау ысулларына өйрәтә. Консультация барышында табиб тарту сәбәпле организмда теге яки бу чирнең килеп чыгу куркынычын, никотинга бәйлелек дәрәҗәсен билгели. Табиблар дәваланганнан соң да тәмәкене ташлый алмаучыларга кирәкле хәлиткеч адым ясарга ярдәм итә.

Яңалык

Июнь үзгәрешләре

▶ Инде хәбәр иткәнебезчә, Россия Президенты Владимир Путин кушуы буенча, 1 июньнән эшләмәүче пенсионерларның пенсиясе һәм яшәү минимумы 10 процентка арта. Шулай итеп, Россиядә пенсиянең уртача күләме 19360 сумга җитәчәк. Барлыгы 35 миллион өлкән кеше өстәмә алачак.

Моннан тыш, туендыручысын югалту буенча пенсия түләү чоры арттырыла: мәктәпне тәмамлаган, әмма югары яки урта уку йортына кермәгәннәргә бу түләү 1 сентябрьгә кадәр озайтыла.

▶ Гаммави хакимиятнең бердәм системасы турында закон үз көченә керә. Аның нигезендә, төбәкләр депутатлары һәм башлыкларының бердәм вәкаләтләр срогы билгеләнә. Ул 5 ел тәшкил итәчәк. Шул ук вакытта субъектлар төбәк башлыгының вәкаләтләре срогы санын үзләре билгели алачак. Законда Президентның Федерация субъектлары җитәкчеләрен, ышанычны җую сәбәпле, эштән алу хокукы билгеләнә, шулай ук төбәкләр башлыкларына карата «президент» атамасын куллануны тыю кертелә.

▶ Каты чирләрдән интегүче балаларны дәвалау җиңеләя. Онкология, гематология һәм башка шундый каты чирләрдән интегүче балаларны, дару инструкциясендә «балаларга ярамый» дип күрсәтелсә дә, шуның белән дәваларга рөхсәт ителәчәк. Эш шунда: бүген яман шеш авыруларыннан интегүче балаларны дәвалау зурларны дәвалауга караганда кыенрак. Сәбәбе – сабыйлар өчен дару ассортиментының күпкә ярлы булуы. Фармацевтика компанияләренә кечкенә дозировкалы дарулар белән клиник сынауларны кат-кат үткәрү отышлы түгел. Шуңа күрә аларның күбесе дару инструкциясендә «балаларга куллану өчен тыела» дип кенә күрсәтә дә, шуның белән шул. Нәтиҗәдә онкологка һәм гематологка яшь пациентларны зурлар өчен билгеләнгән дарулар белән

Илдар Мөхәммәтҗанов

дәваларга туры килә. Күп балалар өчен исән калуның бердәнбер мөмкинлеге бу. Әмма медицина оешмасын иминият компанияләре тикшергән очракта, оешмага баланы дәвалаган өчен акча 100 проценты белән түләнмәскә мөмкин.

▶ Банкта, иминиятләштерү компанияләрендә, элемтә операторлары, дәүләтнеке булмаган пенсия фондларында паспорт урынына машина йөртү таныклыгы гына да күрсәтергә мөмкин булачак.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Анатолий АКСАКОВ, Дәүләт Думасының Финанс базары комитеты рәисе:

Ипотека хәтта гадәти программалар буенча 11 процентка кадәр төшә. Гәрчә әле күптән түгел генә ташламалы ипотека да 12 процент белән генә бирелә иде. Хәзер 9 процентка калды. Әмма ул, тагын да кимеп, 7 процент чамасы калыр дип уйлыйм. Кулланучылар кредитлары да арзанайды – уртача 2 процентка. Бу, һичшиксез, уңай күренеш, чөнки икътисадны үстерергә ярдәм итәчәк.

(«Парламентская газета»)

РОССИЯДӘ – ЯЛ

«Работа.ру» хезмәте Россиядә яшәүчеләрдән җәйне ничек үткәрергә җыенулары турында белешкән.

39%........ял алырга җыенам

38%........ял алмыйм, эшлим

23%........әлегә планлаштырмыйм

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

БЕЗ АШЛАМА САТАБЫЗ, СЕЗ САНКЦИЯЛӘРНЕ АЛАСЫЗ

Россия ягулык фронтында көрәшне үзенчә алып бара. Газга сумнар белән түләүдән баш тарткан илләргә зәңгәр ягулык озату туктатыла. Польша, Финляндия, Болгария, Голландия, Дания Себер газыннан колак кактылар инде. Башка илләр түләүнең Кремль тәкъдим иткән схемасы белән килешергә мәҗбүр булдылар. «Сумнар белән түләү» дип аталса да, алар барыбер «Газпромбанк»ка евролар күчерәләр күчерүен, банк үзе «Газпром»га акчаны сумнарга әверелдереп бирә. Хикмәт монда кайсы валюта белән түләүдә түгел, кайсы банкка түләүдә. Хисап Көнбатыш банклары аша барса, теләсә кайчан аны бикли алалар. Мәскәү газ акчасын үз банкында саклап, аны иминлек белән тәэмин итә, бары тик шул гына. Әлегә бу «газ сугышы»нда откан бер генә ил шәйләнә. Ул – Сербия. Президент Вучич үз иленең өч ел дәвамында Россия газын башка Европа илләренә караганда 10–12 тапкыр арзангарак алачагын әйтте. Россия өчен моның әҗере никадәрдер, әйтүе авыр. Хәер, валютаның күпләп Россия банкында җыелуы да зур файда китерми әлегә. Товар белән тәэмин ителмәгән валюта «кәнфит кәгазе»нә генә әйләнә. Аны чын акчага әверелдерү өчен, санкцияләрдән арынырга кирәк. Мәскәү бу юнәлештә көрәшне үзенчә алып бара. Тышкы эшләр министры Лавров, Африкага барып, кара континент илләреннән, Россиягә санкцияләрне туктатуны сорап, Көнбатышка басым ясауларын үтенде. Әлегә нәтиҗәсе күренми.

Мәскәү икенче уен картасы – глобаль азык-төлек кытлыгы кылларында уйнау аша санкцияләрне алдыру омтылышын да ясап карый. Кара диңгезне Украина кораблары өчен бикләп, ашлык сатуга аяк чалу өчен җаваплылыкны Кремль тулысынча үз өстенә алды. Россия диңгез юлларын ашлык сәүдәсе өчен ачарга риза, әмма алмашка санкцияләрне алуны таләп итә. Әмма Евросоюз таләпкә буйсынырга җыенмый.

Азык-төлек өлкәсендә исә бөтендөнья фаҗигасе оештырырга маташалар. АКШта язгы чәчү темплары бик акрын бара. Барлык уңышның өчтән ике өлешен җыючы Миннесота һәм Төньяк Дакота әлегә барлык мәйданның 11 һәм 27 процентында гына иген чәчте. Бу бик аз. Дөньяда бодай кытлыгына дөге дефициты да килеп өстәлергә җыена. Иң күп дөге экспортлаучы илләрнең берсе – Һиндстан аны читкә сатуга тыю кертергә уйлый. Аның өлешенә исә 20 миллион тонна дөге экспорты тия. Дөге уңышы Россиядә дә начар булырга охшаган. Краснодар краендагы сусаклагычта су җитешмәү сәбәпле, дөге быел 35 процентка кимрәк җыелыр дип фаразлыйлар. Үткән җомгада Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгында июльдән башлап дөге экспортын туктату турында сөйләшүләр булды. Килеп туган вазгыятьтә Кремль тагын бер нәрсә – ашлама экспорты бәрабәренә санкцияләрне алу тәкъдиме белән чыкты. Ул формуланы да хупларга теләүчеләр күренми.

Россиядә

РОССИЯ НЕФТЕ: ТЫЯРГАМЫ, ЮКМЫ?

Европа бердәмлеге илләре соңгы көннәрдә Россиягә каршы санкцияләрнең алтынчы пакетын килештерә алмыйча гаҗизләнде. Алар үз теләкләренә ирешә алсалар, углеводородлар базарында Россиягә урын бик аз калыр һәм Мәскәү, зур табыштан колак кагып, икътисади яктан коточкыч зур югалтулар кичерергә тиеш булыр иде. Вәләкин Россия нефте Көнбатышның үзе өчен дә бик кирәк һәм аңа эмбарго кертергә тырышу бәяләрнең яңа күтәрелеше нәтиҗәсендә санкцияләр астындагы ил казнасына валюта яңгыры гына яудыра. Шулай да дүшәмбе көнне Евросоюз бик авырлык белән булса да өлешчә тыюларны раслый алды. Моннан соң диңгез портлары аша «кара алтын» озатуга рөхсәт юк, ә нефть үткәргеч торбалар аша әлегә кудырып була. Бу очракта да нефтьне нигездә Венгрия генә алырга тиеш. Башка илләр ел ахырына кадәр Себердән килгән җир маеннан арынырга ниятлиләр. Әлегә кем отуын, кем оттыруын әйтү кыен. Эмбарго нәтиҗәсендә «кара алтын»га бәяләрнең 150 долларга кадәр үсешен фаразлыйлар. Дүшәмбедә үк баррель 120 долларлык чикне узып китте. Әмма мәсьәлә алай бик гади үк түгел. Нефть бәясенең рекордлы үсеше моңарчы гел глобаль кризиска этәргеч бирә һәм ахыр чиктә бәяләр кискен түбәнгә тәгәриләр иде. Ләкин хәзер бик күп акча басылды, шуңа күрә бәяләрне фаразлау кыен. Шулай да аларны түбәнгә ыргытырга мөмкин булган берничә фактор бар. Бердән, Көнбатыш эзлекле рәвештә Якын Көнчыгышның «кара алтын» державаларына басым ясый. Согуд Гарәбстанына, мәсәлән, ярыйсы гына бонуслар вәгъдә итәләр. Хәтта утраулар белән бүләкләү вәгъдәсе дә бар. Гарәпләрнең исә нефть чыгаруны кискен арттырырга мөмкинлекләре җитәрлек. Икенчедән, югары нефть бәясеннән башка да рецессия мәйданга чыгып килә. Хәзер Европада да аның билгеләре күренә башлады.

Кытай – ягулык бәяләрен югарыга этүче төп локомотив – үсешенең югары ноктасына җитеп, түбәнгә таба юл тота. 1961 елдан соң беренче тапкыр 2022 ел нәтиҗәләре буенча ул илдә халык саны кими башлар дип көтелә. Аларның демографик упкыннан чыгарлык җайлары юк, чөнки коммунистлар алып барган «бер гаилә – бер бала» дигән юләр сәясәт нәтиҗәсендә бала табарлык хатыннар дефицитта. Кытай икътисады исә кулланучылар саны артуга нигезләнгән.

Өченчедән, Көнбатышта бушлай кредит өләшү сәясәтен туктатырга җыеналар. Европа Үзәк банкы төп ставканы күтәрергә тели. Төп ставканы күтәрү моңарчы һәрвакытта да фонд базарының җимерелүенә һәм глобаль кризиска китерде. Фонд базары аннан башка да икеләтелгән сальто ясап, түбәнгә оча инде. Акча югалткан инвесторлар, ачыргаланып, көтелмәгән адымнарга баралар. Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә, криптовалюталар буенча белгеч киңәшен тотып, 30 миллион доллар югалткан 6 инвестор «киңәшче»нең өенә бәреп керделәр, югалткан акчасын кайтарып бирүне таләп иттеләр. Билгеле инде, хәсрәт белгечнең миллионнары табылмаган, компенсация өчен бары тик 200 мең долларын, кыйммәтле сәгатен һәм ювелир эшләнмәләрен генә талап чыгып киткәннәр. Бай каракларны суд 6 ай төрмәгә хөкем иткән. Менә шундый гасабиланулар саны киләчәктә геометрик прогрессия тәртибендә артачак. Шулай булгач, якындагы бер еллык горизонтта углеводородлар бәясе белән ниләр булыр, үзегез уйлап карагыз.

ТӨП НИГЕЗНЕ НЫГЫТАСЫ

РОССИЯ ИМИНЛЕК СОВЕТЫНЫҢ КҮЧМӘ УТЫРЫШЫНДА АВЫЛ ҺӘМ ДЕМОГРАФИЯ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШТЕЛӘР

Эшлекле сөйләшү

Татарстан халкының 23 проценты салада яши. Сер түгел, бу сан кимүгә таба бара. Идел буе федераль округы төбәкләрендә иминлекне саклау мәсьәләләре буенча киңәшмәдә Татарстан Президенты шулай дип белдерде. Авылсыз булмый, моны һәркем белә, ә авыл саклансын өчен нишләргә? Утырышта шул һәм башка мәсьәләләргә тукталдылар.

Билгеле булганча, бу көннәрдә Татарстан башкаласына Россия Иминлек советы секретаре Николай Патрушев килде. Ул кичә эшлекле очрашулар оештырды, Казан Кремлендә Көнбатыш чикләүләре шартларында Россиянең транспорт һәм энергетика куркынычсызлыгы мәсьәләләре, Идел буе төбәкләренең социаль-икътисади үсеше өчен кабул ителгән чараларны гамәлгә ашыру турында фикер алышты, Идел буе федераль округы төбәкләрендә иминлекне саклау мәсьәләләре буенча киңәшмәдә катнашты. Бүген исә Тәтеш районына сәфәр кыла.

Кичәге утырышта авыл территорияләрендә тормыш сыйфатын арттыру һәм демография мәсьәләсен күтәрделәр.

Николай Патрушев әйтүенчә, авыллардагы тормыш рәвеше шәһәрнекеннән калыша. Шуңа да, бәлки, авылларның яңа типлары турында уйланырга кирәктер. Бу очракта инфраструктура һәм башка уңайлыклар да исәпкә алынырга тиеш, билгеле.

– Ил күләмендә андый мисаллар бар, шул исәптән Татарстанда да салада яхшы үсеш алган инфраструктуралы яңа җирлекләр барлыкка килүе мәгълүм. Авыл җирендә вазгыятьнең яхшыруы кешеләрнең шәһәргә күченеп китүен киметәчәгенә ышанам, – диде Иминлек советы секретаре.

Авырткан җирләрне барлауны дәвам итсәк, авылда яшәүче күпчелекнең кереме яшәү минимумыннан азрак, эшсезлек дәрәҗәсенең зур булуын әйтергә кирәктер.

tatarstan.ru

Кадрлар кытлыгы да кала бирә. Моны Россия Президентының Идел буе федераль округындагы тулы вәкаләтле вәкиле Игорь Комаров та таныды. «Соңгы биш елда Идел буе округында авылда яшәүчеләрнең кимү күрсәткече ике мәртәбә артты. Авыл һаман да шәһәрләрдән керем күләме, тирә-юньне төзекләндерү юнәлешләре буенча калыша», – диде ул утырышта.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та төбәктәге вазгыять турында хисап тотты.

– Республика халкының 23 проценты авылда яши. Шуңа да без авылдагы тормыш сыйфатын күтәрүгә аерым игътибар бирәбез. Әлеге эш республикакүләм төрле программалар кысасында алып барыла, – диде республика җитәкчесе. – Узган ел Татарстанда 50 млрд сумга 44 программа тормышка ашырылды. Шуның 7 миллиард сумы авыл җирлекләрендә объектлар төзүгә юнәлдерелде. Бу елда да шул күләмдә акча тотылачак.

Рөстәм Миңнеханов сүзләренчә, шәһәрдәгеләрдән аермалы буларак, авылда яшәүчеләр тизрәк гаилә кора, бала тудыра. Әйтик, социаль ярдәм чараларын саклап калу бәрабәренә, 2020 елда туучылар кимүен туктату мөмкин булды. Моның нәтиҗәсе буларак салада туган балаларның артуын әйтергә мөмкин.

Чикләр билгеле

Чикләр билгеләнде, хезмәттәшлек турында килешенде. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның Башкортстан башлыгы Радий Хәбиров белән кичәге очрашуы әнә шуның белән истә калачак. Күрше республика җитәкчесе Казанга Россия Иминлек Советы секретаренең Идел буе федераль округындагы уртак күчмә утырышында катнашу өчен килде.

Очрашу кысасында ике килешү имзаланды. Беренчесе – Башкортстан Республикасы һәм Татарстан Республикасы арасында чикнең урнашу урынын билгеләү турында. Икенчесе – Татарстан Республикасы Хөкүмәте һәм Башкортстан Республика Хөкүмәте арасында сәүдә-икътисади, фәнни-техник, социаль һәм мәдәни хезмәттәшлек турында 2019 елның 18 апрелендә имзаланган Килешүне тормышка ашыру буенча 2022–2024 елларга чаралар планы турында.

«Без төбәкләр өчен ике мөһим документ имзаладык. Бу безнең хезмәттәшлекне ныгытырга ярдәм итәчәк», – диде Татарстан Президенты. Башкортстан башлыгы әйтүенчә, хәзерге шартларда төбәкара хезмәттәшлек аерым роль уйный. Ике төбәк арасындагы товар әйләнеше 34,3 млрд сумга җиткән.

ХЕЗМӘТ КЕШЕСЕНӘ – УҢАЙЛЫ ШАРТЛАР

Яңалык

«Сибур» компаниясе Түбән Камада ял үзәге төзергә җыена. Хезмәт кешесенә карата мөнәсәбәтне үзгәртүне күздә тота ул. Нефтехимикларның Кара диңгез ярында корпоратив ял итү мөмкинлеге дә барлыкка килгән. Шәһәрдә тагын ниләр үзгәрәчәк?

Район башлыгы Рамил Муллин «Түбән Кама Нефтехим» социаль объектларына бәйле үзгәрешләр турында сөйләде. «Сибур» беренче чиратта медицина инфраструктурасына җитди өлеш кертергә планлаштыра. Бу завод медицинасына да, профилактик медицинага һәм диспансерлаштыруга да кагыла. 1 млрд сумнан артык акча җиһазлауга, яңартуга, белгечләрне җәлеп итүгә тотылачак. Медицина объектларын яхшырту өчен ныклы база булачак бу. Рамил Муллин белдергәнчә, «Сибур» гамәлгә ашырырга планлаштыра торган социаль проектлар шәһәрнең сәнәгать мәйданчыгы һәм социаль корылмалар буенча вазгыятьне тамырдан үзгәртәчәк. Әлеге инфраструктурага 10 меңнән артык кеше җәлеп ителәчәк. Аларның гаиләләрен дә исәпкә алганда, якынча 30–40 мең кеше дигән сүз.

– Киләчәктә бездә шәһәрдәге сәламәтлек саклау системасы белән уртак система булыр дип өметләнәм. Бу хакта министрлык белән фикер алышачакбыз. Һәрхәлдә, җиһазларны яңарту буенча җитди планнар булуы куандыра, – ди җитәкче.

Түбәнкамалыларны «Корабельная роща» шифаханәсенең киләчәге дә кызыксындыра икән. Рамил Муллин билгеләп үткәнчә, бирегә әлеге оешманы үзгәртеп коруга да бәйле үзгәрешләр көтелә. Бу уңайлыклары күп булган шифаханә булачак. Гомумән, «Сибур» ял үзәге төзергә планлаштыра. Анда «Юность» савыктыру һәм «Олимпиец» спорт лагерьлары да керәчәк.

Компания планнарына туклану системасын үзгәртү дә керә. Предприятие тирәсендәге ашханә мәйданнарын яңартуга зур акча тотылачак. «Сибур»ның планы – һәркем өчен уңайлы булган һәм сәламәт туклануга юнәлдерелгән эш рестораннары булдыру. Шулай ук көнкүреш биналарыннан алып, санитар бүлмәләргә кадәр предприятиенең башка сервислары системасы да яңартылачак.

– Без мондый әйберләргә бик игътибар итмибез. Әмма театр элгечтән башлана. «Сибур» да барыннан да элек хезмәт кешесе өчен уңайлы шартлар тудыра, – ди Муллин.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Туклану һәм кунакчыллык индустриясен үстерүгә мөһим өлеш кертүе, актив иҗтимагый һәм хәйрия эшчәнлеге өчен «ТАТИНТЕР РЕСТОРАНТС» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры, Казан шәһәре һәм Татарстан Республикасы рестораторлары һәм отельерлары ассоциациясе президенты **Гаязов** Зөфәр Фәдип улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

* * *

Гаилә институтын ныгытудагы һәм балалар тәрбияләүдәге казанышлары өчен Баулы муниципаль районы буенча Потапово-Томбарлы авылыннан тугыз баланың ата-анасы **Фәрваев** Юрий Фәйзелхак улы, **Фәрваева** Татьяна Сергеевна; Кукмара муниципаль районы буенча Югары Күзмис авылыннан җиде баланың ата-анасы **Искандиров** Юрий Александрович, **Искандирова** Ирина Петровна; Казан шәһәре муниципаль берәмлеге буенча Совет районыннан ун баланың ата-анасы **Верниковский** Леонид Эдуардович, **Верниковская** Раиса Викторовна; Саба муниципаль районы буенча Байлар Сабасы шәһәр тибындагы поселогыннан тугыз баланың ата-анасы **Сәгыйтов** Фәргать Тәлгать улы, **Сәгыйтова** Гөлнара Әмир кызы; Чистай муниципаль районы буенча Чистай шәһәреннән җиде баланың ата-анасы **Рыбочкин** Андрей Анатольевич, **Рыбочкина** Лариса Юрьевна **Татарстан Республикасының «Ата-ана фидакарьлеге» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыруга лаеклы өлеш кертүләре өчен Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең мобилизация эше буенча ярдәмчесе **Ибәтуллин** Наил Равил улы, «Түбән Кама шәһәренең бердәм заказчы дирекциясе» муниципаль бюджет учреждениесенең җәмәгатьчелек белән эшләү буенча баш белгече **Орлова** Лариса Алексеевна, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы **Сираев** Рафаил Мөдәррис улы, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Тәтеш шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе **Тегулев** Андрей Владимирович, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Мәмәшир авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре **Хәлиуллина** Илзирә Зиннәтулла кызы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы **Ханнанова** Әнисә Атлас кызы **«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«Олы Кариле» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте механизаторы (Татарстан Республикасының Кама Тамагы районы) **Әхмәтҗанов** Наил Төхфәт улы, «Август-Кама Тамагы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең авыл хуҗалыгы производствосы тракторчы-машинисты (Татарстан Республикасының Кама Тамагы районы) **Гафаров** Радик Таһир улына, «Заря» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте механизаторы (Татарстан Республикасының Буа районы) **Федоров** Валерий Михайловичка, «СУРНАИ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте механизаторы (Татарстан Республикасының Балтач районы) **Хафизов** Илдус Салих улына **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы»** дигән мактаулы исем бирелде.

Июнь үзгәрешләре

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

▶ Спорт ярышларын карау өчен «җанатар картасы» (Fan ID электрон документы) пәйда булачак. Әлегә рәсми ярышларга гына кагыла бу. Аларның исемлеген Хөкүмәт раслаячак. Спорт ярышларына билетларны шушы карта белән сатып алырга кирәк булачак. Тамашачылар стадионга махсус турникет аша кертеләчәк. Моңа кадәр ярышлар вакытында җәмәгать тәртибен бозучыларга мондый карта бирелмәячәк.

▶ Ике тапкыр һәм аннан күбрәк хөкем ителүчеләр һәм исерек килеш рульдә тотылучылар өчен коралга лицензия бирелмәячәк. Моннан тыш 21 яшькә кадәр корал сатып алу тыела. Фәкать дәүләт хәрби оешмаларында хезмәт итүчеләргә, хезмәт эшчәнлегендә коралдан файдаланучыларга, ату спорты белән шөгыльләнүчеләргә генә рөхсәт ителәчәк.

▶ Урманда янгын чыгуга гаеплеләр өчен штраф күләме арта. Хәзер ул гади кешеләргә – 30 мең сумга (моңа кадәр 3 мең сумга кадәр иде), вазыйфаи затларга – 50 мең сум, юридик затларга 400 мең сумга җитәчәк. Янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозу янгынга китергән очракта, штраф күләме гади кешеләргә – 50 мең сумнан 60 мең сумга кадәр, вазыйфаи затларга – 110 мең сумга кадәр, юридик затларга 1 миллионнан 2 миллион сумга кадәр тәшкил итәчәк.

▶ Магистратура программалары буенча бюджет урыннары саны арттырылачак. Хөкүмәт аларны арттыру буенча карар кабул итәчәк.

ӨМӘ ТӘМАМ: ӘЛМӘТ БЕЛӘН АПАС – БЕРЕНЧЕ!

eco.tatarstan.ru

Республикада 1 апрельдән чистарту икеайлыгы башланды. Экологлар инде нәтиҗә ясый: Татарстанда ике ай эчендә 34 мең «КамАЗ» машинасы чүп чыгарылган. Акция кысасында 1 миллион 300 төп агач утыртылган.

– Ике ай дәвамында республикада яшәүчеләр, табигать саклау хезмәтләре, предприятие һәм оешмалар вәкилләре чистарту һәм тәртип урнаштыру эшенә актив кушылдылар. Беренче көннәрдән үк шәһәрләрдә, районнарда һәм бистәләрдә табигатьне саклау акцияләре, массакүләм өмәләр, экологик дәресләр үткәрелде. Икеайлык вакытында барлыгы 1,5 меңгә якын экологик акция узды, – диде Татарстанның экология һәм табигать ресурслары министры Александр Шадриков.

Министр сүзләренчә, экологик чараларда 19 меңнән артык техника катнашкан. Полигоннарга ике ай эчендә 510 мең кубометр чүп чыгарылган, бу – 34 мең «КамАЗ» машинасы дигән сүз. Инде хәбәр иткәнебезчә, икеайлык кысасында республика өмәсе дә үткәрелгән иде. Ул апрельнең 24ендә узды. Бу чарада 253 мең кеше катнашып, 41 мең кубометрдан артык чүп җыелган.

Александр Шадриков республика халкы бик актив дип билгеләп үтте. «Өмәгә чакыруга чыгалар. Чистарту акцияләрендә үз өлешен керткән һәркемгә чиксез рәхмәт», – диде ул. Министр «Экология» илкүләм проекты кысасында уздырылучы «Россия суы» бөтенроссия акциясе турында да сөйләде. Ул чара «Идел көне»нә багышланып, берьюлы Казанда, Волгоградта, Түбән Новгородта һәм Самарада узды. Һава торышы уңайсыз булуга карамастан, акциядә йөзләгән кеше катнашты. Казан анда катнашучылар саны буенча беренче урынны алган. 2021 елда Татарстан ел йомгаклары буенча әлеге чарада абсолют җиңүче булды. Быел бу акция октябрь ахырына кадәр дәвам итәчәк.

Татарстанда чистарту икеайлыгында иң актив катнашкан район-шәһәрләрне дә котладылар. «Шәһәр тибындагы поселок, район үзәге, авыл статуслы муниципаль районнар» категориясендә 1 нче урынны – Апас, 2 нче урынны – Балтач, 3 нче урынны Биектау районы алды.

«Шәһәр статуслы районнар» категориясендә 1 нче урында – Әлмәт, 2 нче урында – Минзәлә, 3 нче урында – Кукмара. «Шәһәр округлары» категориясендә 1 нче урынны – Казан, 2 нче урынны Чаллы шәһәренә бирделәр.

ТОРМЫШ ЧӘЧӘКЛӘРЕ

Бүген – Халыкара балаларны яклау көне. Инде берничә көн алдан бәйрәм уңаеннан сабыйлар өчен күңел ачу чаралары башланды. Һәр баланың иртәләре сөенеч белән башлансын, киләчәкләре якты булсын иде. Язмышлары газетада бәян ителгән балалар белән без даими элемтәдә. Аларның берничәсеннән шушы көннәрдә хат алдык. Тормышларында матур үзгәрешләр барлыгын белеп сөендек. Сезгә дә әлеге хатларны тәкъдим итәбез.

Әнием җылысында рәхәт

Мин – тумыштан авыру. Аякларым йөрми. Табиблар, һәрдаим күнегүләр ясау кирәк, ди. Әнием бу хакта интернетка язып чыккан иде. Шуны күреп, безгә газетадан шалтыраттылар. Без «ВТ» коллективы белән дуслашып киттек. Аннары инде минем сәламәтлегемне яхшырту өчен зур суммада акча кирәк булды. Шул чакта «Йөрәктән – йөрәккә» дигән хәйрия концерты уздырдыгыз. Концертка гаиләбез белән килгән идек. Әле ул вакытта тамашачылар үземә дә күп итеп акча бирде. Аллага шөкер, мин йөри алмасам да, утырырга, кашык тотып ашарга, рәсем ясарга, язарга, матур итеп сөйләшергә өйрәндем.

Тормышымда күңелсез хәл дә булды. Әтием белән әнием аерылышты. Әмма шуңа да карамастан, әти мине ташламый. Хәлемне белеп, ярдәм итеп тора. Газетада минем хакта язма чыккач, ярдәм итүчеләр күбәйде. Җырчы Алсу һәм Азат Фазлыевлар дәвалану өчен 250 мең сум акча бирделәр. Әле дә һәр җомга саен сезнең газетаны укучылар акча күчерә.

Мин өйдән генә укыйм. Абыем мәктәпкә йөри. Авыру бала булсам да, үземне яратуларын тоям. Әни кочагында бигрәк рәхәт.

Айзат ШӘМИЕВ.
Буа

Әби-бабайга рәхмәт!

Әтием белән әниемне «Булгария» фаҗигасендә югалттым. Кечкенә булсам да, әти-әнисез калуның нинди зур кайгы икәнен аңладым. Әмма әби-бабайларымның, туганнарымның мине яратуы аркасында ятимлек ачысын сизмим. Быел 8 нче сыйныфны тәмамладым. Биш яшемнән «Сөембикә» бию түгәрәгенә йөрим. Җитәкчебез Илһамия Гыйләҗиева безне хәрәкәт серләренә өйрәтә. Күп тапкыр бәйгеләрдә җиңдек. Быел исә туганым Гүзәл белән «Йолдызлык» («Созвездие») бәйгесендә биеп, беренче урынны яуладык. Бу биюне укытучыбыз Рәдиф Исмәгыйлов өйрәткән иде. Әле күптән түгел коллективыбыз белән Йошкар-Ола шәһәренә барып кайттык. Бик күңелле сәфәр булды. Июнь аенда ансамблебез белән Сочига җыенабыз.

Биеп кенә йөрмим, әби-бабама да булышам. Әниемнең әнисе белән аралашам. Хәлләрен беләм. Киләчәктә күңелдә йөрткән теләкләремә ирешәсем килә. Нинди теләкләрме? Анысы сер булып калсын әле.

Алмаз ХӘЙРЕТДИНОВ.
Арча

Хыял яшәтә мине

Күпләрегез минем хакта «Ватаным Татарстан» газетасы битләреннән укып белгәндер дип уйлыйм. Язмыш мине журналист Гөлгенә апа Шиһапова белән таныштырып бәхетле итте. Ул көнне хәтерлим әле. Гөлгенә апаны эш белән без йөри торган тернәкләндерү үзәгенә җибәргәннәр иде. Ул минем хәлемне сораштыргач, «Иң зур хыялың нинди?» – дип сорады. Мин исә, җырчы Салават Фәтхетдинов һәм Айдар Галимовны күрәсем килә, дидем. Ике көннән без инде Салават абыйда кунакта идек. Ә аннары бер атна да үтмәде, Айдар Галимов концертына чакыру алдым. Бу ике җырчы белән әле дә элемтәдә торам. Салават абый мине аеруча үз итте. Үзенең концертларына чакыра, әле менә күптән түгел, Сочига барганда, матди ярдәм күрсәтте. Һәр уңышымны аның белән бүлешәм. Күптән түгел аның студиясенә барып, ике җыр яздырып кайттым.

Быел 9 нчы сыйныфны тәмамладым. Әлегә имтиханнар тапшырып йөрим. Теләгем – 11 сыйныфны тәмамлап, Казан дәүләт мәдәният институтына укырга керәсем килә. Театрны бик яратам. Кайбер спектакльләрне утызар тапкыр карадым. Ятлап та бетердем инде. Әгәр югары белем алсам, үзем кебек ДЦП диагнозлы авыру балалар өчен театр студиясе ачар идем. Мине шул хыял яшәтә. Теләгем кабул булса, бушка да эшләргә риза! Шөкер, әти-әнием мине көчле рухлы булырга өйрәтеп үстерде. Беркайчан да, булмас, моны эшли алмам, дип күңелемне төшермим. Тирә-ягыбызда яхшы



күңелле кешеләр күп. Алар һәрчак ярдәм кулы сузып тора. Димәк, әле минем йөрәк түрендә йөрткән бик күп хыялларым чынга ашачак.

Анель ИМАМИЕВ.
Казан шәһәре



Үткәннәрне онытасым килә

Мин «Ватаным Татарстан» газетасы белән 5 яшемдә таныштым. Кинәт кенә авырып киттем. Табиблар мине бары тик катлаулы һәм кыйммәтле операция генә коткара дигәннәр. Шул операциядән соң мин гадәти тормышка кайттым, дисәм дә була. Гаиләбез белән сөенеп туя алмыйбыз. Аллага шөкер, мин исән-сау. 2 нче сыйныфны тәмамладым. Сеңлем белән бер сыйныфта укыйм. Чиреккә ике генә «4ле» чыкты. Ике чит тел өйрәнәм. Быелдан яңадан бер телне өйрәнергә җыенам. Элек шөгыльләнгән гимнастикама кире кайттым. Зурлар белән бергә шөгыльләнеп, II разряд алдым. Сәламәтлегемне дә гел кайгыртып торабыз. Табибларга еш күренәм, Мәскәүгә дә тикшеренергә барабыз. Мондый тормыш рәвешенә ияләндем инде. Кайчан нинди анализ бирәсен дә белеп торам. Кечкенә генә булсам да, мин тормышны яратып яшәргә өйрәндем. Дөньяга башкача карыйм. Гаиләбез белән көн саен йоклар алдыннан әбиебез өйрәткән догаларны укып, авыр чакта ярдәм кулы сузган һәр кешегә яхшы теләкләр телибез. Бер генә теләгем бар – балалар авырмасын иде!

Лилиана САБИРОВА.
Казан

ӨЙЛӘНҮ ТҮГЕЛ СӨЙЛӘНҮ

Гаилә ныклыгын пар балдаклар гына саклыймы? Татарстанның ЗАГС идарәсе һәм Мәдәният министрлыгының уртак коллегиясендә шул хакта фикер алыштылар. Баксаң, бу юнәлештә хисләр генә түгел, мәдәният тә, сәнгать тә, үрнәк тә, матди ярдәм дә бик мөһим икән.

tatmitropolia.ru

Соңлап кавышу нәтиҗәсе

Татарстанда гаилә корырга һәм бәби алып кайтырга бик ашыкмыйлар. ЗАГС идарәсе әнә шундый зарын белдерде. Саннар сагайта, әлбәттә: 30 ел эчендә бала туу күрсәткече – 19, никахлашулар 23 процентка кимегән. Ә гаилә таркалу очраклары 25 процентка арткан!

– 2022 елның дүрт аенда Татарстанда бәби табу очраклары кими башлады. Барлыгы 11,8 мең бала туу очрагы теркәлде. Бу узган елның шушы чоры белән чагыштырганда 8 процентка кимрәк, – диде ЗАГС идарәсе башлыгы Гөлшат Нигъмәтуллина. – Бу инде беренче генә ел күзәтелә торган күрсәткечләр түгел. 1990 нчы елларның моңсу чорына әйләнеп кайтабыз, бу чорда да туучылар саны үлүчеләрдән азрак иде.

Мондый вазгыятьтә «Нишләргә соң?» дигән сорау кабыргасы белән килеп баса. Гөлшат Нигъмәтуллина бу җәһәттән уңай үзгәреш юлына илтәчәк берничә сукмакны билгеләргә тырышты.

– Тискәре тенденцияне булдырмас өчен, медицина һәм мәгариф оешмалары белән берлектә гаилә кыйммәтләрен саклауга юнәлдерелгән чаралар оештырыла. Шулай ук мәгълүмати кырда эшне көчәйтергә кирәк. Ил Президенты Владимир Путин да, күпбалалы гаилә Россия өчен матур традиция булырга тиеш, дип белдерде. Шул традицияне кире кайтарырга, безгә әнә шундый үрнәкләрне күрсәтергә кирәк, – диде идарә җитәкчесе.

Бәби туучылар аз булмас та иде, гаилә коручылар юк. Гөлшат Нигъмәтуллина китергән саннарга ышансаң, республикада ир һәм хатын булып яшәүчеләр саны бу елның гыйнвар – апрель айларында 3,7 процентка кимегән. Аерылышу мәсьәләсе дә борчый. Моннан иң элек бала зыян күрә бит. 4,4 меңләп бала ата-анасы аерылышу ачысын татыган. 2021 елда андыйлар саны 9,5 мең булган.

Тулы гаиләдә тәрбияләнмәгән балалар да шактый. Төгәлрәк әйткәндә, Татарстанда андыйлар – һәр алтынчы. Кайбер җирлекләрдә тулы булмаган гаиләләрдә туган балалар саны артуга таба да бара икән.

– Былтыр андыйлар саны 6,5 мең булса, быел шундый 1,9 мең баланы теркәдек. Әйтик, Тукай, Югары Ослан, Әлки районнарында бу сан арта бара, – диде Гөлшат Нигъмәтуллина.

Мәдәният тә әһәмиятле

ЗАГС идарәсе билгеләгән мәсьәләләрнең чишү юлын мәдәният һәм сәнгать өлкәсеннән дә табарга була. Татарстанның мәдәният министры урынбасары Юлия Әдһәмова бу уңайдан башкарыла торган эшләр турында сөйләде.

Республикада 3,7 меңнән артык мәдәният учреждениесе эшли. Былтыр гаилә белән карарлык, катнашырлык 650ләп чара оештырганнар. Татарстан театрлары куя торган һәр өченче спектакль дә балалар өчен икән.

Гаилә кыйммәтләрен алга сөрү, бергәләп ял итү юнәлешендә күргәзмә, китапханә, музей, фестиваль һәм милли бәйрәмнәр дә әһәмиятле урын алып тора, дип саный Юлия Әдһәмова. Алар башкарган эшне санап тормыйбыз, «бернәрсә дә юк» дип әйтерлек түгел. Кайбер мәдәни оешмаларга гаилә абонементлары булу да үз нәтиҗәсен бирә. Аның электрон форматтагысын эшкә җигү турында уйлана министрлык. Моннан тыш, балалар арасында «Пушкин картасы» популяр.

– Республика бу картаны кулланучылар саны буенча алдынгылар рәтендә. Сүз уңаеннан, безнең төбәктәге мәдәни чараларга уртача билет бәясе – 445 сум, – диде министр урынбасары.

Хисләр өстенрәк

Мәдәнияттән җиргә төшсәк, «Яшь гаиләләрне нәрсә борчый?» дигән сорауга әйләнеп кайтабыз.

Яшьләр нинди сәбәп белән гаилә кора? Коллегиядә яңгыраган статистикага күз салсак, аларның 56 проценты бергә яшәү өчен рәсми рәвештә никахлаша. 27 проценты хисләрнең җитдилеген раслау ниятеннән бер гаилә булып яши башлый. 4 проценты, тиздән бала туу сәбәпле, гаилә булып теркәлеп калырга тырыша.

Гаилә булып яши башлагач, киртәләр дә очрамый калмый. Шуларның иң зурысы – торак мәсьәләсе (44 процентында шул мәшәкать). Гаилә эчендәге мөнәсәбәтләр каршылыгы белән яшь парларның 14 проценты очраша икән. Финанс авырлыкларга 17 проценты дучар.

– Иң сөендергәне шул: асылда Татарстан яшьләре мәхәббәт һәм хисләр бәрабәренә гаилә коралар. Шулай да торак мәсьәләсе алар өчен төп сорау булып кала бирә, – диде республиканың яшьләр эшләре буенча министр урынбасары Алла Кондратьева.

Яшьләр эшләре министрлыгы Татарстанның яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү программаларында катнаша. 2022 елда федераль программа буенча бүлеп бирелгән акчаның 93 проценты үзләштерелгән инде. Министрлык Татарстан өчен бу ташламалы лимитны арттырып булмасмы дип тә уйлана. Федераль программадан тыш, республикада «Яшь гаилә» дигәне эшләп килә. Аның ярдәмендә парларга елына 7 процентлы кредит белән торак сатып алу мөмкинлеге бирелә. Программадан 1,7 мең яшь гаилә файдаланган. 1102се яңа фатирлы булган.

Торак мәсьәләсеннән мөнәсәбәтләргә күчсәк, яшьләр арасында аерылышу очраклары турында да әйтми калып булмый, билгеле. Хәер, аңа бәйле аерым статистика юк. Алла Кондратьева бу җәһәттән ЗАГС идарәсеннән ярдәм сорады.

– Гаилә таркалуларның яртысыннан артыгы яшь, берничә ел гына торган гаиләләргә туры килә. Статистика алып барылса, без башлангыч этапта ук чарасын күрер идек, – диде ул.

Тәкъдимнәре арасында цифрлы психологик-педагогик ярдәм дигәне яңгырады. Аңлашудан аерылышуга бер адым калганда, яшьләргә кемнеңдер тыңлап, киңәш бирүе дә мөһим бит әле ул.

– Бу тәкъдимебезне Президент хуплады, без заманча технологияләр буенча консультация бирәчәкбез. Һәр районда да психологик-педагогик ярдәм үзәкләре юк бит, – диде Алла Кондратьева.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

«БЕЗДӘН НИНДИ ЯРДӘМ КИРӘК?»

БАЛТАЧТА ТУГАН ТЕЛЛӘРНЕ САКЛАУ ҺӘМ ҮСТЕРҮ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШТЕЛӘР

Балтачта Татарстан Президенты каршындагы татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясенең зона семинары үтте. Туган телләрне саклау һәм үстерүдә милли мәгариф, мәдәният һәм социаль өлкәләрдәге эшчәнлек турында сөйләштеләр.

– Балтачны сайлавыбыз очраклы түгел, – диде комиссия рәисе Марат Әхмәтов. – Белгәнегезчә, комиссиянең исеме дә, аңа йөкләнгән миссия дә үзгәрде. Без хәзер Татарстанда яшәүче башка милләтләрнең телләрен саклау өчен дә тырышырга тиеш. Балтач – күпмилләтле район. Төп халкы татарлар булса да, биредә удмуртлар, марилар да күп, башка милләт вәкилләре дә бар. Районда туган телләрне өйрәтү, башка халыкларның да телен, динен, йолаларын саклау юнәлешендә башкаларга үрнәк булырдай эшләр, башлангычлар шактый.

Марат Әхмәтов бу урында берничә телдә белем бирүче Чепья мәктәбен, шушы көннәрдә генә 55 нче тапкыр үткән, күрше өч республика балаларын берләштереп торучы матур бер традициягә әйләнгән «Дуслык» учагын, районда татар теле укытуның сыйфатын, дини оешмаларның белем һәм тәрбия юнәлешендә куйган хезмәтләренә югары бәя биреп, башкаларга үрнәк итеп күрсәтте. «Күпләребезгә бу юнәлешләрдә эшчәнлекне көчәйтергә кирәк. Авылларда ата-аналарның туган телгә мөнәсәбәте ул дәрәҗәдә үк агрессив түгел әле, ә менә район үзәкләрендә бу юнәлештә эшне арттырасы бар. Бу эшләрдә укытучылар, мәктәп коллективлары үзләре генә без көткән нәтиҗәгә ирешә алмаска да мөмкин. Әгәр дә без, көймәгә утырып, тыныч кына, үзе барыр әле дип көтсәк, телебезне югалтырга да мөмкин. Район җитәкчелеге югарылыгында, барлык структуралар бергә эшләгәндә генә алдыбызга куйган бурычларны үти алачакбыз. Һәр район үзәгендә, һәр районда милли белем һәм тәрбия кайнап торган, миллилек ташып торган кимендә бер мәктәп, бер балалар бакчасы булырга тиеш. Югарыдан кунаклар килгәндә генә, атналар буе әзерләгән төркемнәр яки мәктәпләр түгел, чынбарлыкта шушы рух белән яши торган коллективлар кирәк безгә», – диде ул.

Статистикага караганда, болай борчылыр урын да юк кебек. Соңгы өч елда бу уңайдан күрсәткечләрдә шактый уңай үзгәрешләр бар. Тик татар сыйныфлары ачылып та, дәреслекләргә, методик ярдәмлекләргә заказлар булмау комиссиядәгеләрне шикле уйларга этәрә. «Бездә элекке дәреслекләр бар, шулар белән укытабыз», – дигән җаваптан гына алар канәгать түгел. Бу уку елында мәгариф учреждениеләре, мөгаен, алай дип кенә котыла да алмастыр. Комиссиянең балалар бакчаларына, башлангыч сыйныфка, бишенче сыйныфка укучылар кабул итү кебек юнәлешләрдә инде саллы анализлары бар. Бөтен нәрсә чагыштыруда ачык күренә, бу саннар арасында эзлекле бәйләнеш булырга тиеш, дип саный алар.

Балтач районында дини оешмаларның, дин эшлеклеләренең шушы юнәлештә куйган эшчәнлеген үрнәк итеп, комиссия рәисе башкаларга да бу өлкәне әле тулы куәткә файдаланылмаган көч дип тәкъдим итте. Җәлил хәзрәтнең берүзе башкарган хезмәтен дә Марат Әхмәтов шушы өлкәдә сыйфат күрсәткече, ягъни башкалар омтылырга тиешле биеклек, планка дип бәяләде.

Хәтерләсәгез, моннан берничә ел элек Җәлил хәзрәт туган авылы Бөрбашка керү юлында куйдырган «Онытың белән нинди телдә сөйләшәсең?» дигән баннер республикада зур яңгыраш тапты. Аның «игезәк туганнары» хәзер күп урында очрый. Күчмә утырышта катнашучылар бу көнне Бөрбашта булып, Җәлил хәзрәтнең авылны, динне, телне саклауда куйган хезмәтләренең нәтиҗәләрен үз күзләре белән күрде. Интернат-пансионат, балалар бакчасы, урта мәктәп... – аларның һәркайсының эш тәҗрибәсе аерым өйрәнергә лаек. Балалар бакчасы белән танышканнан соң Марат Әхмәтов: «Телне үстерү, тәрбия юнәлешендә бездән нинди ярдәм кирәк?» – дип сорагач, бакча мөдире: «Безнең бөтен мөмкинлекләр дә бар», – дип, соңгы елларда откан грантлар, шулар ярдәмендә алынган әсбап-җиһазлар, кайтарылган татарча китаплар, балалар өчен энциклопедияләр... турында сөйләп китте. «Җәлил хәзрәт авылы булганга гына шулайдыр, безнең әле бөтен балалар бакчалары да мондый хәлдә түгел», – дип шаяртты Марат Әхмәтов.

«Нинди ярдәм кирәк?» Пленар өлештә саф татар телендә чыгыш ясаган Чепья урта мәктәбенең удмурт теле һәм әдәбияты укытучысына да шул ук сорауны бирде комиссия рәисе. Аннан да ниндидер зарлану ишетелмәде. Кече Лызи урта мәктәбе, Карадуган гимназиясе, Балтач үзәк мәчетендәге «Мәгърифәт мәркәзе» белән танышканнан соң, кунаклар, бәлки, бер Бөрбашта гына түгел, бу юнәлешнең башка урыннарда да матур өлгеләре, нәтиҗәләре барлыгына ышангандыр.

Район башлыгы Рамил Нотфуллинның бу юнәлештәге эшчәнлек буенча чыгышы, бәлки конкрет мисаллар белән баетылгангадыр, комиссия әгъзаларында зур кызыксыну уятты. Район башлыклары арасында да, залда утыручы кунаклар арасында да яңалык булып тоелган фикер-чараларны язып төшереп алучылар булды. Әмма вазгыятьнең һәр урында да шулай булмавын искәртеп, Марат Әхмәтов аннан соң чыгыш ясаган Мәгариф һәм фән министрлыгының милли мәгариф идарәсе башлыгы Лилия Әхмәтҗановага: «Безне хәзер җиргә төшерегез инде», – диде. Дөрес, бу көнне тәнкыйть гомуми формада гына булды, беркем дә комиссия каршына басып, җавап тотмады. Һәркем үз гаебен аңлар, дип ышандылар булса кирәк. Бәлки бу кадәресе өйгә эш итеп кабул ителгәндер.

...Утырышта сүз күбесенчә яңа уку елы турында барды. Бүгеннән әти-әниләр белән эш башламасак, соңга калуыбыз бар – төп фикерләрнең берсе шул иде.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Язучы фикере

Көтүче

Көннәр бераз җылынып, аяк асты яшәрә башлау белән авыл халкы арасында чыш-пыш китә торган иде элек: «Быел Фәлән-фәлән кешеләр сайланырга җыена икән, кайсына тавыш бирәбез?» Бу сүз капка төпләрендә җыелган күрше-күлән арасында да калкып чыга. Сайланырга җыенучыларны энәсеннән җебенә кадәр тикшерәләр. Кайсы елда кемне сайлаганнар, алар күпме хак сораган, ничегрәк эш башкарган... Берсе дә читтә калмый. Безнең ише малай-шалай авызын ачып тыңлап тора. Кызык чөнки, Фәлән-фәлән абзыйларның ниндирәк кеше икәнен бары тик шунда гына тулысынча белеп калырга мөмкин. Бераздан сүз капка төпләреннән узып, урам очындагы җыенга күчә. Менә ул чын мәгънәсендә демократик җыелыш була торган иде. Һәркем үз сүзен әйтә, бернәрсәне дә яшереп тормый, беркемгә яраклашмый. Анысын-монысын тикшергәннән соң, күпчелек тавыш белән дәгъвачыларның берсен сайлап куялар. Көтүче итеп.

Көтүче ул җәй көне авылның иң абруйлы кешесе була. Кайтуына көтүче чираты төшкән йортта, соңгы тавыкларын суеп булса да, кунак итәләр, берәр рүмкә салып та бирәләр. Икенче көнгә катомкасын тутырып, хәзинәдә булган затлы ризыкларын төяп җибәрәләр. Ул заманда халык малны ару гына асраса да, ашау-эчү ягы такы-токырак иде кебек. Йомырка бүле инде, бәрәңге, дөге ярмасы, карабодай... Ит мәсьәләсе кыенрак, тавык суйсалар да, аны я печән кайтаруга, я көтү чиратына багышлабрак чалырга тырышалар. Хәллерәк кешеләр сарык та эш итеп куя анысы. Былтыргыдан калган тозланган ит тә була. Какланган каз да сакланып калырга мөмкин. Тик барыбер бөтенесе дә чиклерәк, сакланып тотыла торганрак иде. Һәрхәлдә, хәзерге кебек муллык түгел инде. Шуңа күрә көтүченең ашау-эчү ягын мулрак итеп хәстәрләргә омтылалар иде.

Соңга табарак «көтүче чираты» дигән төшенчә юкка чыкты. Ул инде өй буенча чиратка керми, үзенә кайтып ашый, көндәлек ризыгын да үзе хәстәрли. Ә тора-бара «көтүче сайлау» дигәне дә онытылды. Чөнки авылда көтү көтәргә атлыгып торучылар бик калмады. Бер кеше булса да бик әйбәт әле, ә аны инде сайлап торасы түгел, бәясен генә билгеләргә кирәк. Акча арзанланып, бәяләр бик зур кебек күренә башлагач, көтү көтәргә теләүче бөтенләй калмады. Файдалы түгел. Яздан син, әйтик, мал башына йөз тәңкә дип сөйләшәсең, ә көз җитүгә, теге йөз сумга бер кап чәй дә тими. Шуннан халык үзе чиратлап көтү көтәргә мәҗбүр булды.

Безнең кебек шәһәрдә яшәгән яшь-җилкенчәккә монысы да кызык тоела иде. Элек маллар күп булгач, урам саен диярлек берешәр көтү булыр иде. Сыерныкы, бозауныкы, сарыкныкы. Шул көтү чиратларының барысын бер тирәгәрәк туры китерергә тырышалар. Кем генә кайда гына эшләсә дә, көтү чираты җитәсе көнгә алдан ук ял алып куя. Моңа каршы килеп торучы җитәкчеләр булмый диярлек. Шәһәрдә дә гадәттә шул ук авыл кешеләре тора бит инде. Аңларга тырышалар. Көтү чираты өч-дүрт көнгә китсә, авыл кешесенең барлык балалары кайта. Үзенә күрә бер бәйрәм шикелле була.

Маллар уҗымга кереп йөдәтмәсә, көне туры килсә, көтү чиратының бик авырлыгы юк инде. Урман-кырларда йөрисең, төш җитүгә елга буендагы комлыкка алып төшәсең. Шунда су коенасың, балык тотасың. Кич җиткәнче шул комлыкта ятучы елгыр кешеләр дә була торган иде. Шундыйрак бер мәзәк тә йөри безнең якта. Пыр тузышып печән әзерләгән халыкка бер шаян көтүче әйтә икән:

– Сарыкларыгызга печән әзерләмәгез быел, ком әзерләгез, мин аларны ком ашарга өйрәттем.

Гел елга буенда комлыкта ята икән теге. Тагын бер абзый көтү чиратыннан кайтып кергән дә хатынына кычкыра икән, имеш:

– Хатын, тизрәк сыерга башак бир, югыйсә ачтан үлә.

Күңелле булган инде ул дәвер. Үзең мал асрамасаң да, әле иртән чыбыркы тавышына, малларның кычкырышуына уянып китәсең... Ә кичләрен... Авыл очында көтү күренү белән бала-чагалар урам тутырып шул якка йөгерешергә тотына. Олыраклар капка төбенә чыгып утырып маллар кайтуын көтә. Дөнья хәлләрен сөйләшәләр, яңалыклар уртаклашалар, киңәш-төңәш итәләр. Боларның барысы да үзенә күрә авылның бер бизәге кебек тоела.

Файдасы да булган көтүнең. Урман-кырларны чистарту вазыйфасын да башкарган. Ул чакларда болыннар такыр, тыкрык буйларында, ындыр артларында чүп үсеп утырмый торган иде. Барысын да мал-туар ризык итеп бетерә. Хәзер үзең чистартып тормасаң, шундук чүп үлән күмеп китә. Ә урманга аяк та басарлык түгел, чытырман басып бетергән.

Менә шул чакларны искә төшереп, капка төбендә утырам. Авыл матур инде, йортлар төзек. Ләкин бар дөньяны тынлык баскан. Урамнан кеше үткәне дә сирәк кенә. Кем беләндер күрешәсе, аз гына сөйләшеп аласы килә. Ичмасам, күрше дә өйдә юк, Себергә эшкә киткән. Көтү кайтыр алдыннан урам кешеләр белән тулыр кебек тоела. Алар кемнеңдер эскәмиясенә җыелып гәп корып җибәрерләр... Кай арададыр бала-чагалар пәйда булыр да уйнаклый-уйнаклый авыл очына чабарлар... Авыл шау-гөр килеп торыр. Тыкрык буеннан, «Майка! Майка!» дип бозавын чакыра-чакыра, саңгырау Сәвия апа килеп чыгар. Бозаулары «Лайка» кушаматлы аларның, эт алырга рөхсәт итмәгәч, уллары Наил шулай кушкан. Ә Сәвия апа чукрак булгач, үзенчә ишетәдер инде, гел «Майка» дип чакыра.

Тын авыл урамы буйлап төрле хатирәләр генә чабыша. Ә көтү кайтмый да кайтмый.

Марат КӘБИРОВ

Реклама

БАР ДА СҮЗДӘН БАШЛАНА

ФИЛАРМОНИЯДӘ «ТАТАR СҮЗЕ» БӘЙГЕСЕНӘ НӘТИҖӘ ЯСАЛДЫ

Мондый матур телне югалтып буламыни? Сүзе булса, аны җиткерүчесе булса, югалмас ул. Икенче мәртәбә уздырыла торган «Татаr сүзе» бәйгесе быелга шундый күтәренке ноктада йомгакланды. Аның инде сыйфат һәм дәрәҗәсе дә югарырак, географиясе дә киңрәк. Италия, Төркия, Казахстан, Азәрбайҗан, Белоруссия... Быел бәйге төрле яшьтәге дүрт меңгә якын татарны берләштерде.

Кирилл Буздалов

Гомере озын булсын

«Татаr сүзе»нең жюри рәисе, Татар дәүләт филармониясенең сәнгать җитәкчесе Айдар Фәйзрахманов быелгы катнашучыларның әзерлеген югары бәяләде:

– Аваз җибәрсәң, ул кайтаваз булып әйләнеп кайта. Шуның шикелле беренче бәйгенең дә күркәм кайтавазы булды. Бу кайтаваз балаларны, яшьләрне, профессионалларны уятып җибәргәндәй итте. Быелгы катнашучыларның әзерлеге бик югары дәрәҗәдә. Мөгаен, алар беренче бәйгене күреп, нәтиҗә ясагандыр. Чыгышларын музыка, видеосурәтләр белән озата бару, оста режиссура татар сүзен куәтләп җибәрәләр. Катнашучыларның мәктәп программасыннан «китүе» дә сөендерә. Узган елгы кебек Муса Җәлил һәм Габдулла Тукай шигырьләре генә укылмады. Хәзерге заман авторларына мөрәҗәгать иткән, эзләнгән катнашучылар, – дип сөйләде ул безгә. – «Татаr сүзе» гомерле булсын иде. Телебезне генә түгел, милләтебезне саклауның мөһим өлеше ул. Бар нәрсә дә сүздән башлана. Сүз белән әйтемнәребез, мәшһүр язучыларыбызның иҗаты, җырларыбыз, милләтебезнең яшәеше бәйләнешле. «Татаr сүзе» белән матур яшәүгә, дуслыкка өндәп, балаларыбызга телебезнең аһәңен иңдереп, татар булулары белән горурлык хисләрен сеңдерергә насыйп булсын иде.

Халкыбыз телебезнең, сүзебезнең киң даирәдә яңгырашына шулкадәр сусаган. Бәйгенең жюри әгъзасы, профессор Фоат Галимуллин шундый фикердә.

– Бәйгедә катнашучыларның сәнгатьле башкару осталыгы күтәрелгән. Репертуар сайлау мәсьәләсенә, сәнгатьле уку нечкәлекләренә кагылышлы киңәшләребез исәпкә алынган. Билгеле, кимчелекләр бөтенләй юк түгел иде. Әмма сайлап алырга мөмкинлек зуррак булды. Быелгы бәйгегә яңа номинация кертелде – катнашучылар үзләре иҗат иткән әсәрләрен укыды. Профессиональ шагыйрьләр белән беррәттән, башлап язучылар да катнашты. Һәм, әйтергә кирәк, әсәрләренең күбесе кайтыш түгел, бәйгегә бик җаваплы килгәннәр иде, – диде ул. – Аннан соң, узган ел профессиональ артистлар да азрак катнашкан иде. Быел сөендерделәр. Гомумән алганда, быелгы бәйгенең нәтиҗәләре бик куандыра. Алга таба да эшне шушылай дәвам иттерсәк иде. Татар телен саклау һәм үстерүнең бик тә мөһим һәм әһәмиятле юлы бу.

Гади бәйге генә түгел

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов «Татаr сүзе»н комиссиянең иң уңышлы һәм отышлы проектларының берсе дип атады.

– Милләттәшләребезне шушы вакыйгага күпләп тартып кертә торган, телебезнең әдәби матурлыгын халыкка җиткерә алган иң зур бәйгеләрнең берсе ул. Киләчәктә әлеге проектны тагын да киңәйтергә, аны тыңлаучы һәм караучыларны арттырырга ниятлибез. Бәлки, ул зур гына телевизион проект буларак тәкъдим ителер, – диде ул журналистларга.

Комиссия рәисе сәхнәгә соңыннан, җиңүчеләрнең барысын диярлек тыңлаганнан соң гына күтәрелде. Бу бәйгене сәнгатьле укучылар бәйгесе дип кенә атау аз түгелме икән? Марат Әхмәтов үзенә дә, безгә дә бирде бу сорауны.

– Чыгыш ясаучылар әйтерсең үзләре укыган әсәрләренең язмышы белән яши. Нинди талантлы безнең татар халкыбыз! Ә бит катнашучыларның күбесенең хезмәт вазыйфалары сәхнә, иҗат белән бәйләнмәгән. Шундый иҗатыбыз булганда, ул иҗатны шушындый дәрәҗәдә ачып биргән талантларыбыз булганда, халкыбызның киләчәге дә бар. Мондый матур телне югалтып буламыни? – диде ул.

Дөрестән дә, филармония сәхнәсендә чыгыш ясаучылар үзләре сайлаган әсәрләрне бик лаеклы башкарды. Үз тормышларын шигырьгә салып сөйләүчеләр дә бар иде. Шигъри гаиләләр арасында II урынга лаек булган Нурмөхәммәтовлар гаиләсе – шундыйлардан. «Дустыбыз, шагыйрь Фәнил Гыйләҗев безнең гаиләгә багышлап «Гомеребез» шигырен иҗат итте. Мин үзем чигү чигәм, «Казан сөлгеле» проектын алып барам, ә тормыш иптәшем – көрәшче (көрәш буенча дөнья чемпионы Азат Нурмөхәммәтов. – **Ред.**) Шигырьнең эчтәлеге дә татар халкының йөзек кашы – көрәшкә һәм татар хатын-кызларына хас булган һөнәргә багышланган», – дип сөйләде Гөлнара Нурмөхәммәтова.

Шигырьне алар ике кечкенә уллары белән башкарды. Гаилә башлыгы сүзләренчә, өйдә бары тик татарча аралашкач, тормыш рәвешен шулай алып баргач, балаларына шигырь өйрәтү һәм, гомумән, бәйгедә катнашу бик җиңел булган. «Катнашучылар бик күп иде. Җиңүчеләр арасына керүебез белән бик горурланабыз. Татарны без мәдәнияте, көрәше, дине, фәне белән көчле, дибез. Аның көче – сүзендә дә. Бу сүзне еракларга яңгыратырга, аның көчен арттырырга насыйп булсын», – диде Азат Нурмөхәммәтов.

Күңелендә шигырь йөрткән кешеләр мондый бәйгенең барлыгын ишетми кала алмый. 18 яшьтән өлкәнрәк катнашучылар арасында «Проза» номинациясендә җиңгән Гүзәл ханым Шакирова шундый фикердә. «Узган елгы бәйгедә мәсәл сөйләп, II урын алган идем. Быел Туфан Миңнуллинның «Майбәдәр батыр»ыннан өзек сөйләдем. Икесе дә – кыз чагымда ятлаган әсәрләрем. Бүген миңа – 65, һәм алар әле дә хәтердә саклана. Быел мин җиңәрмен дип уйлап та карамадым. Җиңәчәгемне сәхнәгә чыгып, кулыма диплом алганчы белмәдем, оештыручылар сер итеп саклады», – дип, хис-тойгылары белән уртаклашты ул.

Бәйгедә катнашучыларның чыгышларын бөтен Татарстан күрергә тиеш. Марат Әхмәтов шундый фикердә. Аларны QR-код рәвешендә махсус буклетларга туплап, республика буйлап таратырга ниятлиләр.

Бәйгедә, «Профессионаллар» номинациясендә I урынны – Ришат Әхмәдуллин, II урынны – Эмиль Талипов, Артём Пискунов, III урынны Динар Хөснетдинов алды. Үз шигырьләрен сөйләүчеләр арасында иң осталары булып Гөлүсә Батталова, Булат Ибраһимов, Нурия Бәширова, Алинә Шәгәрәева, Алмаз Хәмзин танылды.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

«Татаr сүзе» – саннарда

✓ Быел бәйгедә барлыгы **3557** кеше катнашкан. **II** турга **310** катнашучы сайлап алынган. Шуларның 40ы – җиңүчеләр.
✓ Иң яшь катнашучыга **2** яшь булса, иң өлкәненә – **102** яшь.

ҖИҢҮЧЕЛӘРНЕҢ ТУЛЫ ИСЕМЛЕГЕ – VATANTAT.RU САЙТЫНДА

ӨЙДӘН-ӨЙГӘ КИТАП ИЛТӘ...

Баулы, Татар Томбарлысы

Укысыннар гына! Баулы районының Татар Томбарлысы авылы китапханәчесе Эльвира Әхмәтҗанова өчен китапны өйдән-өйгә йөреп укытуның бер авырлыгы да юк. Иң яшь абунәчесенә – 2, иң олысына – 82 яшь. Китапханәгә гаиләләре белән йөрүчеләр дә бар. Баулыга баргач, китапханәченең тәҗрибәсен үзебез күреп кайттык.

Туган тел хакына...

Авылда китап белән дуслык бетмәгән әле. Әнә ялгыз яшәүче 70 яшьлек Әмирҗан абый Моратхуҗин китапханәгә көн саен эшкә йөргән кебек бара. Иртүк сәгать 7дә китапны кулына алган була инде ул. Күпбалалы Мустаевлар гаиләсе дә атна саен йөрергә ияләнгән. 82 яшьлек Венера әби Гыйлаҗева да өйдә генә утыра торганнардан түгел. Китап укымыйча түзә алмыйм, ди. Үзләре килә алмаганнар да игътибардан читтә калмый.

Дүрт баласын ияртеп, китапханәгә йөргән Зөлфия Мустаева милли җанлы булып чыкты. Әлегә ул декрет ялында, белгечлеге буенча – хисапчы. Татар авылы булса да, сабыйларның теле русча ачылу, бакчада үзара шул телдә сөйләшүләре борчый аны. Татар телен авыррак өйрәнүләрен дә яшерми. Шуңа күрә атна саен китапханәгә бармыйча калмыйлар. Кечкенә якта балалар инде китап дөньясына чума. Андагы маҗаралар белән яши башлыйлар. Эльвира апалары бәйрәмгә дә чакырып тора икән.

– Балаларда кечкенәдән үк китапка мәхәббәт тәрбияләргә тырышабыз. Кич хикәяләр, әкиятләр укыйбыз. Ике яшьлек Мәрьямебез китап укымыйча йокларга ятмый. Китапханәгә барыйк, дип кенә тора. Әле күп сүзләр белми, өйрәнә. Иң олысы Азалиягә – 10 яшь. Үзем дә китап укырга бик яратам. Китап кибетенә йөрибез, бергәләп сайлап алабыз. Өйдә китапханәбез бар. Ай саен берничә китап булса да сатып алабыз. Укыгыз дип әйтеп торам, – ди Зөлфия.

«Укучы зәвыгын беләм»

– Унбер ел эшлим, китапханә икенче өемә әйләнде. Авыл халкының нәрсә укырга яратканын яхшы беләм. Төрле яшьтәге китап укучылар белән аралашу ошый миңа. Китап бирү генә түгел, клуб хезмәткәрләре белән төрле чаралар үткәрәбез. Бакчага, мәктәп укучылары янына барабыз. Өлкәннәрнең өенә дә китап илтәм. Арада йөри алмаучылар да бар. Берсен дә рухи азыктан нәүмиз итәсем килми. Ике-өч көннән укып бетергәч, тагын кирәк, дип шалтыраталар. Ял көне дип тормыйм, берәүгә дә каршы килмим, – ди сөйкемле сөякле Эльвира. – Китапханәгә 20ләп газета-журнал килә. Пенсионерларга бушлай, башкаларга берничә көнгә түләүле итеп бирү мөмкинлеге бар. Яңа китаплар тәкъдим итәбез, төрле темага очрашулар, бәйрәмнәр уздырабыз. Соңыннан бергәләп чәй эчәбез. Авылны, китапханәне яратканга, эшем бара. Район, республика бәйгеләрендә дә катнашырга тырышам. Күптән түгел 100 мең сум грант оттым, әлеге акчага яңа шкафлар сатып алдым, яңа челтәрләр элдем. Кешене җәлеп итү өчен матурлык та мөһим.

Эльвира иң тугры абунәчесе Әмирҗан абыйны да искә төшермичә калмады. Ул бер көн килми башласа, әллә авырып киткәнме икән, дип борчыла башлый икән. «Узган ел ике атнага Кырымга ял итәргә киттем. Почта хезмәткәренә, газеталарны өйгә кертерсең, дип әйтеп калдырдым. Әмирҗан абый, безгә килеп, барлык газеталарны да укып барган. Аңа бөтен яңалыкны газетадан белергә кирәк. Көнендә укымаса, икенче-өченче көнне аңа ул кирәк түгел», – ди Эльвира Әхмәтҗанова.

Кечкенәдән китап белән җенләнгәннәр картлык көнендә рухи азыксыз тора алмый. Әлбәттә, андыйлар рухи азыкны интернеттан да, телевизордан да эзләми.

Ризидә апа Бәдриева авыл мәктәбендә 46 ел татар теле һәм әдәбияты укыткан. Аңа – 77 яшь. Россиянең атказанган укытучысының күпне белү теләге әле дә кимеми. Тик тезләре авырткач, бик йөри алмый шул.

– Элек китапханәгә үзем бара идем. Хәзер Эльвира китерә. Минем укучым ул. Сораган китабым китапханәдә булмаса, аптырап тормый, районныкына барып алып кайта. Ни арада өлгерәдер, шаккатам. Мәктәптә эшләгәндә, барлык әдәби кичәләрне үткәрә иде. Берсендә балалар китапханәгә ашыга. Фәнис Яруллинның кичәсен оештыра икән. Хәзер дә кечесен дә, олысын да җыеп тора. 24 ел каенана белән яшәп, соңгы елларда аны тәрбияләде. Аркасына күтәреп, мунчага алып керә иде хәтта. Андый киленнәр сирәк. Игелеге һәркемгә дә җитә аның, – дип мактый мөгаллимә укучысын.

Ризидә апа соңгы вакытта Әмирхан Еники әсәрләрен кабат укып чыккан, Һади Такташ шигырьләрен искә төшергән. 65 яшьлек Расиха апа Сафиуллина исә Мәдинә Маликова, Зифа Кадыйрова әсәрләрен яратып укый икән.

– Бик әйбәт китап булса, көнгә икене дә укый алам. Җәй көне бакча эшләре белән мәшгуль. Яңгырлы көннәрдә кулдан китап төшми инде. Интернетта утырган юк. Кино карауга караганда, күбрәк китап укуны яратам. Файдасы да зур. Хәтерне яхшырта. Яшь чактан ук килә бу гадәт. Эльвира кебек китапханәчеләр булганда, без китап укудан туктамабыз, – ди Расыйха апа.

Сәрия МИФТАХОВА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 7057 данә
Гомуми тираж – 16016 данә
Газетага сертификат бирелде
Заказ 276

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+